**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге составына керүче Норлат торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**

14 ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Норлат авыл җирлегенең Норлат авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә –Норлат авылында зиратны төзекләндерү (инвентарь сатып алу, чүп үләнен бетерү) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2023 елның 14 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә 190 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 115 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 112 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 3 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге составына керүче Норлат авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип таныргa.

2. «Норлат авыл җирлегенең Норлат авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә –Норлат авылында зиратны төзекләндерү (инвентарь сатып алу, чүп үләнен бетерү) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип таныргa.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Норлат авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Норлат авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: ___________ М.Х.Закиров

Норлат авыл җирлеге
башлыгы ___________________ М.Х.Закиров